**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июля 2021 с. Тюлячи № 231

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 3 октябрендә кабул ителгән 921 номерлы «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын төзү һәм реестрын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен, Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашу өчен гаризаларның критерийларын бәяләү өчен шкалалар раслау турында» карары, автобус маршрутлары паспортлары нигезендә, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 23 июнендәге 01-20/4089 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

1.1. 1 номерлы «Максабаш ав. - Теләче ав.» даими йөртүләр муниципаль маршруты, озынлыгы 16 км.

1.2. 2 номерлы «Лесной пос. - Теләче ав.» даими йөртүләр муниципаль маршруты, озынлыгы 19 км.

1.3. 3 номерлы «Әбде ав. - Теләче ав.» даими йөртүләр муниципаль маршруты, озынлыгы 38 км.

1.4. 4 номерлы «Шәдке ав. - Теләче ав.» даими йөртүләр муниципаль маршруты, озынлыгы 25 км.

1.5. 5 номерлы «Олы Нырсы ав. - Теләче ав.» даими йөртүләр муниципаль маршруты, озынлыгы 35 км.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелгәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 маендагы 357 номерлы «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты белән билгеләнгән ике һәм аннан да күбрәк гомуми тукталыш пунктына ия даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын билгеләү яисә үзгәртү тәртибен раслау турында» карары нигезендә, билгеләнгән муниципаль маршрутларны гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары Реестрына кертергә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевкә йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин